РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 21**

**КАРАР**
**«17» мая 2019г.**

Теләче муниципаль районы Башлыгының 2010 елның 13 августындагы «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасына муниципаль заказ турында»гы 47 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131 санлы Федераль закон нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Теләче муниципаль районы Башлыгының 2010 елның 13 августындагы «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасына муниципаль заказ турында»гы 47 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

А) исемдәге «яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасына» дигән сүзләрне «өстәмә һөнәри белем» сүзләре белән алыштырырга.

Б) преамбулада Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-599 санлы Указы исемен түбәндәге тәртиптә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем алуга дәүләт заказы турында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-599 санлы Указы.

В) 1-3 пунктларда «яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасына» дигән сүзләрне «өстәмә һөнәри белем» сүзләре белән алыштырырга.

1) «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасына муниципаль заказ турындагы Нигезләмәгә:

А) исемдәге «яңадан һөнәри әзерләүгә, аларның квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасына» дигән сүзләрне «өстәмә һөнәри белем» сүзләре белән алыштырырга.

Б) «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәткәрләрен яңадан һөнәри әзерләүгә муниципаль заказ турындагы Нигезләмәне кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Теләче муниципаль районы Советының аппарат җитәкчесе И. В. Мөбиновка йөкләргә.

И.Ф. Зарипов

Теләче муниципаль районы
Башлыгының
2019 елның «17» мая 21 санлы
карарына Кушымта

«Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем алуга муниципаль заказ турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25 санлы Федераль закон, 2013 елның 5 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында"гы 44 санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турындагы Кодексы, башка федераль законнар һәм Теләче муниципаль районы Уставы, Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә, башка норматив- хокукый актлар нигезендә эшләнде һәм «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем алуга муниципаль заказ (алга таба - муниципаль заказ) формалаштыру тәртибен билгели.

2. Муниципаль район Башкарма комитетының кадрлар эше һәм муниципаль хезмәт секторы мөдире (алга таба – кадрлар эше секторы) муниципаль хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белем алуга ихтыяҗы нигезендә төзелгән җирле үзидарә органнарының гаризалары нигезендә муниципаль заказ структурасын билгели һәм аны финанслау күләмен исәпли.

3. Муниципаль заказта түбәндәге белешмәләр бар:

- Татарстан Республикасы территориясендә өстәмә һөнәри программалар буенча, шул исәптән яңадан һөнәри әзерләү һәм квалификация күтәрү өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча, укытырга җибәрелә торган муниципаль хезмәткәрләр саны турында;

- муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирү өчен Теләче муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

- муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне фәнни-методик, укыту-методик һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин итү турында;

- муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирү өчен муниципаль заказны гамәлгә ашыруга гомуми акча күләме турында.

4. Муниципаль заказ кадрлар секторы тарафыннан түбәндәгеләргә нигезләнеп исәпләнә:

- укырга җибәрелә торган муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт вазыйфаларының категорияләре һәм төркемнәре, өстәмә һөнәри

белем алу юнәлешләре, төрләре, формалары һәм сроклары буенча бүленеп фаразланыла торган саны;

- өстәмә һөнәри белем бирү хезмәтләре бәясенең икътисадый нормативлары;

Муниципаль заказ календарь елына, 1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәрге чорга (алга таба - исәп-хисап елы) исәпләнә.

Кадрлар укытуга ихтыяҗны исәпләгәндә, муниципаль заказга кертелми:

- хисап елында муниципаль хезмәтне туктатуны күздә тотучы муниципаль хезмәткәрләр;

- югары уку йортларында, аспирантурада муниципаль хезмәттән аерылмыйча укучы муниципаль хезмәткәрләр;

- хисап елында озак елларда (йөклелек һәм бала табу, бала карау буенча ялда) һәм озак хезмәт командировкаларында булучы муниципаль хезмәткәрләр.

Беренче чиратта укырга тәкъдим ителүчеләр составына вазыйфаларга күчәргә кандидатлар булган (югарырак вазыйфаны алыштыру яки башка профильдәге вазыйфага күчү) муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль хезмәткә беренче тапкыр кабул ителгән затлар кертелә.

Муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирү кирәк очракта, кимендә биш елга бер тапкыр уздырыла.

5. Муниципаль заказ түбәндәге тәртиптә формалаша:

- җирле үзидарә органнары, планлаштырылган елга кадәрге елның 1 сентябренә кадәр, кадрлар эше секторына, муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне килешү өчен, гариза тапшыра (№ 1 кушымта);

- планлаштырылган елга кадәрге елның 15 сентябренә кадәр, җирле үзидарә органнары тапшырган гаризалар һәм муниципаль хезмәткәрләрне укытуга булган ихтыяҗны анализлау нигезендә, кадрлар эше секторы № 2 кушымта буенча муниципаль заказ проектын әзерли

- чираттагы финанс елына җирле бюджет проектын формалаштыру өчен Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән срокларда кадрлар эше секторы муниципаль заказ проектын Теләче муниципаль районының финанс-бюджет палатасына чираттагы финанс елына Теләче муниципаль районы бюджеты проектына кертү өчен җибәрә;

- Теләче муниципаль районының тиешле елга бюджеты турындагы карар үз көченә кергәннән соң, оештыру эшләре бүлеге муниципаль заказ күләмен аныклый һәм проектны «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгына раслау өчен тәкъдим итә.

6. Муниципаль заказ «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы тарафыннан раслана.

7. Өстәмә һөнәри белем лицензиясе һәм дәүләт аккредитациясе булган һөнәри белем бирү учреждениеләренә муниципаль заказ урнаштыру «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы 2013 елның 5 апрелендәге 44 санлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Теләче муниципаль районы
муниципаль хезмәткәрләренә
өстәмә һөнәри белем алуга
муниципаль заказ
турындагы Нигезләмәгә
Кушымта № 1

**Форма**

Гариза

____________________________________________________________________

(җирле үзидарә органы исеме) _____ елга муниципаль хезмәткәрләрне өстәмә һөнәри белем алу программалары буенча укытуга

| Муниципаль хезмәт вазыйфаларының категориясе һәм төркеме исеме | Муниципаль орган муниципаль хезмәткәрләренең штаттагы саны (кеше) | | Укытырга җибәрелүче республика муниципаль хезмәткәрләренең саны (кеше) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән алдагы елны муниципаль хезмәткә беренче тапкыр алынучы | Барлыгы | Шул исәптән укыту программалары буенча | | |
| | | | | Яңадан һөнәри укыту | Квалификация күтәрү | |
| | | | | | Барлыгы | Шул исәптән алдагы елны дәүләт граждан хезмәтенә беренче тапкыр алынучы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

Җирле үзидарә органы җитәкчесе ____________ ______________________

«____» ______________ 20__ ел имза (Ф. И. О.)

______________

Теләче муниципаль районы
муниципаль хезмәткәрләренә
өстәмә һөнәри белем алуга
муниципаль заказ
турындагы Нигезләмәгә
Кушымта № 2

**Форма**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүгә муниципаль заказ__________ ел

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирү

| Җирле үзидарә органы исеме | Укытырга җибәрелүче муниципаль хезмәткәрләр саны (кеше) | | | Бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре күләме (мең сумнарда) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | шул исәптән белем бирү программалары буенча | | Барлыгы | шул исәптән | |
| | | яңадан һөнәри белем бирү | калификация күтәрү | | яңадан һөнәри белем бирүгә | калификация күтәрүгә |
| | | | | | | |

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә Татарстан Республикасыннан читтә һәм чит илләрдә өстәмә һөнәри белем бирү

| Җирле үзидарә органы исеме | Укытырга җибәрелүче муниципаль хезмәткәрләр саны (кеше) | Бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре күләме (мең сумнарда) |
|---|---|---|
| | | |

3. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүне фәнни-методик, укыту-методик һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин итү

| Җирле үзидарә органы исеме | Эш һәм хезмәт төрләре | Бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре күләме (мең сумнарда) |
|---|---|---|
| | Муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне фәнни-методик тәэмин итү буенча эш һәм хезмәт күрсәтү | |
| | Муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне укыту- методик тәэмин итү буенча эш һәм хезмәт күрсәтү | |
| | Муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне мәгълүмати-аналитик тәэмин итү буенча эш һәм хезмәтләр күрсәтү | |

4. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирү өчен муниципаль заказны тормышка ашыруга акчаларның гомуми күләме.